ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

02.10.2023 — пос. Октябрьский — 06

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

### Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2023 елның 25 ноябренә халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

   - Ключищи авылындагы поселок юлларында ремонт

   - Су манарасын урнаштыру

   «ӘЙЕ» «ЮК»
3. Ключищи авылы, Колхоз урамы, 95 йорт адресы буенча 10.00 сәгатьтә кибет бинасы янында гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш. Р. Азизов